ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.04.2017 Казан ш. № 76

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында" 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре" 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указлары нигезендә
б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларының үз көчләрен югалтуын танырга:

"Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгы белән расланган конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында" 2011

елның 19 апрелендәге 104 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2011 елның 15 сентябрендәге 221 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2012 елның 13 июнендәге 168 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2013 елның 11 сентябрендәге 255 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2013 елның 14 ноябрендәге 348 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 12 маендагы 165 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 16 июлендәге 213 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 03 февралендәге 30 номерлы;

"Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында" 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 13 октябрендәге 261 номерлы.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2017 елның
07 апрелендәге 76 номерлы
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Дәүләт комитетында конкурс "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында" 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре" 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Дәүләт комитетында конкурс Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба – Дәүләт комитеты рәисе) карары буенча граждан хезмәтенең "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" Федераль закон һәм "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә конкурс нигезендә биләнә торган вакант вазыйфа булган очракта игълан ителә.

1.4. Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелүгә конкурс кадрлар бүлеге тарафыннан, Дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфаларын биләүдә белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Дәүләт комитетында булган кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелүгә конкурс Дәүләт комитетының конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Конкурсны үткәрү турында карар Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан кадрлар бүлеге җитәкчесе әзерләгән дәлилле язмача гариза нигезендә кабул ителә.

Гаризада, конкурсны игълан итү турындагы тәкъдим белән беррәттән, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасының (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы һәм, вазыйфаи бурычларның үзенчәлекләрен исәпкә алып, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре (шушы Нигезләмәгә 1 нче кушымта) булырга тиеш.

1.6. Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

1.6.1. билгеле бер чорга биләнә торган "җитәкчеләр" һәм "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләгәндә;

1.6.2. вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

1.6.3. Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

1.6.4. граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.7. Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Дәүләт комитетының хокукый акты белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

Дәүләт комитеты рәисенең карары буенча, граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

1.8.1. сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

1.8.2. граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

1.8.3. граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Дәүләт комитетының кадрлар резервын формалаштыру.

1.9. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

1.9.1. барлык кандидатларга алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартлар тәэмин итү;

1.9.2. объектив һөнәри критерияләр нигезендә кандидатларны бәяләү;

1.9.3. конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, граждан хезмәте вакант вазыйфалары (кадрлар резервына кертелү) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

## 2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

2.1. Дәүләт комитетында конкурсны үткәрү өчен Дәүләт комитеты рәисенең боерыгы белән даими нигездә гамәл кылучы конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышны үткәрү көнен билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең рәисе тарафыннан конкурс процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составы раслана.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.3. Конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе, Дәүләт комитеты рәисе урынбасарлары, кадрлар бүлеге, юридик бүлек җитәкчеләре, Дәүләт комитетының граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсе җитәкчесе яисә җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Дәүләт комитеты рәисенең гарызнамәсе буенча бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр рәвешендә экспертларның персональ белешмәләрен күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм бүтән оешмаларның вәкилләре керә.

Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Дәүләт комитеты карамагындагы иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан Дәүләт комитеты рәисенең гаризасы буенча тәкъдим ителә.

2.4. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелгәндә конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.5. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.7. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч була.

2.8. Конкурста катнашучыларга карата конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

2.8.1. граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә аеруча туры килә, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү өчен тәкъдим ителә;

2.8.2. граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителә;

2.8.3. граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә туры килми.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм аны граждан хезмәте вакант вазыйфасына билгеләү яисә мондый билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәте вакант вазыйфасына конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе (шушы Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы) белән рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

2.11. Конкурс үткәрүне оештыруны һәм конкурс үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне турыдан-туры Дәүләт комитетының кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## 3. Конкурсларда катнашучылар

3.1. Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган чорда шушы Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Граждан хезмәте вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләмәләргә бәйле рәвештә граждан (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларга таләпләр Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары нигезендә билгеләнде.

3.4. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданы Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

шәхси гариза (шушы Нигезләмәгә 3 нче кушымта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р карары белән расланган рәвештә үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосын (4х6 см) теркәп;

паспортның яки аны алмаштыра торган документның (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт итүгә (эшкә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданның эшкә бәйле (хезмәт итү) эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүнне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

гражданда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп рәвеше);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган

бүтән документлар.

3.5. Дәүләт комитетында граждан хезмәте вазыйфасын били торган, конкурста катнашу теләгeн белдергән граждан хезмәткәре гаризаны Дәүләт комитеты рәисе исеменә тапшыра.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләгeн белдергән граждан хезмәткәре Дәүләт комитетына шәхси гариза һәм үз куллары белән тутырылган, имзаланган һәм граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасын үтә торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы карары белән расланган рәвештә анкета тапшыра, фотосын (4x6 см) теркәп.

3.6. Гражданның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә граждан (граждан хезмәткәре) биләүгә дәгъва кыла торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе исеменә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиешле.

3.7. Конкурста катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан конкурс комиссияләренә конкурсны үткәрү турында мәгълүмати хәбәр "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң 21 көнлек чорда тапшырыла.

3.8. Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

## 4. Конкурсларны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерияләре Дәүләт комитетында граждан хезмәте вазыйфаларына белдерелә торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнде.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләре үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Дәүләт комитетының кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсны үткәрү турында мәгълүмат әзерли һәм "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми

порталындагы Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала: граждан хезмәте вакант вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, граждан хезмәтен үтү шартлары, граждан хезмәте вакант вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатлар тарафыннан Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына тапшырыла торган документларның һәм материалларның исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү дәвам итә торган вакыт, конкурсны үткәрүнең күзалланган вакыты, аның үткәрелү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә:

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлеккә юнәлтелүе, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа кадрлар бүлеге тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача рәвештә хәбәр ителә.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакант вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.4.4. Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яки вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, Дәүләт комитеты рәисе конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул итә.

Кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көннән соңга калмыйча конкурста катнашуга кертелгән кандидатларга аның үткәрелү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр җибәрә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе

тарафыннан карары кабул итү.

4.4.7. Конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт граждан хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган методлардан файдаланып, шул исәптән Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә уздыру юлы белән тест уздыру һәм бүтән төрле конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

4.4.8. Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең билгеле бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Кандидатлар тарафыннан алынган тавышларның саны, кандидатлар шундагы вазыйфага дәгъва кыла торган структур бүлекчә җитәкчесенең фикере Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып торалар.

4.7. Әгәр дә конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле квалификация таләпләренә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яисә яңа конкурсны үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитеты Рәисенең конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган,

граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына карата конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидат ризалыгы белән, аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы карый торган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча кадрлар резервына кертү турында Дәүләт комитеты боерыгы чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Дәүләт комитеты боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр конкурста катнашучыларга конкурс төгәлләнгәннән соң 7 көнлек чорда кадрлар бүлеге тарафыннан язмача рәвештә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре хакында мәгълүмат аны үткәргәннән соң 7 көнлек чорда "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Дәүләт комитетының рәсми сайтында да урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.11. Граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Дәүләт комитеты архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәте вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертелүгә) конкурс үткәрү турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты
Рәисенә
_______________________________________
(инициаллары, фамилиясе)
_______________________________________
(структур бүлекчәнең аталышы)

Гариза.

Дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында

Сездән_________________________________________________________бүлегенең
(бүлек аталышы)
__________________________________________дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын
(вазыйфасының атылышы)
биләүгә конкурс игълан итүегезне сорыйм.

Бу вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучыга карата түбәндәге квалификация таләпләре белдерелә:
______________________________________________________________________

Кушымта: Граждан хезмәте вакант вазыйфасының вазыйфаи регламент күчермәсе.

(биләнә торган вазыйфа)
(имза).
201__ елның «____» ________.

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ
Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе урынбасары
___________________ (_______________)
(имза) (Ф.И.А)

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәте вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертелүгә) конкурс үткәрү турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

____ номерлы конкурс комиссиясе беркетмәсе

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ___________________
_____________________________________________________ биләнә торган вазыйфасына
(структур бүлекчәнең аталышы)
____________________________________ конкурста сайлап алу буенча конкурс комиссиясе
(биләнә торган вакант вазыйфа аталышы)
утырышында тавыш бирү үткәрелде.

Утырышта _____конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1. _________________________________ «риза» _________ «каршы» __________.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
2. _________________________________ «риза» _________ «каршы» __________.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
3. _________________________________ «риза» _________ «каршы» __________.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәсендә________________________________________ конкурс комиссиясе
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
әгъзаларыннан иң күп тавыш җыйды, бу исә тавыш бирүдә катнашкан комиссия әгъзалары санының _______ процентын тәшкил итә.

Конкурс комиссиясе рәисе _________________________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары ___________________________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурс комиссиясе сәркатибе______________________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурс комиссиясе әгъзалары _____________________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

_____________________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурсны үткәрү датасы 201___ елның "___"________.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәте вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертелүгә) конкурс үткәрү турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты
Рәисенә
___________________________________
(инициаллары, фамилиясе)
кемнән_____________________________
___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Яшим:______________________________
___________________________________
Тел._______________________________
(эшнеке, өйнеке)

Гариза.

Мине Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында:________________
____________________________________________________________________________________
(вазыйфа, бүлек, идарә аталышы)
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм.

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә белән, шул исәптән вакант вазыйфага карата белдерелә торган квалификация таләпләре белән таныштырылдым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелү белән килешәм.

Гаризага түбәндәгеләрне терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

| _____________ | _________________ | ____________________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |